**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында» 2004 елның 8 октябрендәге ПУ-614 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 20 июнендәге ПУ-264 номерлы, 2005 елның 10 августындагы ПУ-319 номерлы, 2005 елның 8 сентябрендәге ПУ-362 номерлы, 2007 елның 22 гыйнварындагы ПУ-17 номерлы, 2007 елның 23 августындагы ПУ-453 номерлы, 2007 елның 29 декабрендәге ПУ-717 номерлы, 2008 елның 17 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге ПУ-529 номерлы, 2009 елның 24 октябрендәге ПУ-558 номерлы, 2010 елның 12 февралендәге ПУ-65 номерлы, 2012 елның 18 гыйнварындагы ПУ-22 номерлы, 2013 елның 14 мартындагы ПУ-228 номерлы, 2013 елның 27 августындагы ПУ-830 номерлы һәм 2015 елның 23 ноябрендәге указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлегенең 2 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ*.»;

б) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. «Яңа Гасыр» ТРК» АҖ.»;

в) 14 пунктны төшереп калдырырга;

г) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. «Татавтодор» АҖ*.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 06 май
№ ПУ-260